**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КУШМАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОШМАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.10.2022 Кошман ав. № 10

Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге
җир кишәрлекләрен алмаштыру турында

Хосусый милектәге җир кишәрлегенең муниципаль ихтыяҗлар өчен - су ресурсларын кешеләрнең һәм аларның тереклек эшчәнлеге тискәре йогынтысыннан саклау, пычранган суларның әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын булдырмау, ярларны җимерүдән саклау максатларында гидротехник корылма урнаштыру зарурлыгына бәйле рәвештә, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.21 ст. нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Кайбыч муниципаль районы, Кошман авыл җирлеге адресы буенча урнашкан, «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир» җирләр категориясеннән, «Авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен» рөхсәт ителгән куллану төрендәге категориядән булган гомуми мәйданы 310000 кв.м, 16:21:150403:337 кадастр номерлы җир кишәрлеген Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Кайбыч муниципаль районы, Олы Кайбыч авыл җирлеге адресы буенча урнашкан, «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир» җирләр категориясеннән, «Авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен» рөхсәт ителгән куллану төрендәге категориядән булган гомуми мәйданы 316240 кв.м, 16:21:000000:1190 кадастр номерлы җир кишәрлегенә алмаштырырга.

2. Муниципаль милектәге җир кишәрлеге һәм хосусый милектәге җир кишәрлеген алмашу шартнамәсен төзергә.

3. Милекчеләргә хокуклар турында белешмәләргә тиешле үзгәрешләр кертү өчен кирәкле документларны Татарстан Республикасы буенча Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте идарәсенә (Татарстан Республикасы буенча Росреестр идарәсенең Апас һәм Кайбыч районнары буенча муниципальара бүлеге) җибәрергә тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Кошман авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Л.Р.Сафина